рып даими эшләгәндә дә ял елына 28 көннән дә ким була алмый. Больничный һәм командировка түләүләре гадәти эш форматындагы кебек үк түләнә.

## Туристлар агымын 3,2 млн кешегә кадәр арттыру планлаштырыла

Башкортстанда 2021 елда туристлар агымы күләмен 3,2 млн кешегә кадәр арттыру планлаштырыла. Башкортстанга туристлар агымы ел саен 2-2,5 млн кешегә кадәр тәшкил иткән. 2020 елдагы пандемия чорында, чит ил сәфәрләреннән баш тарту һәм илдә туристик сезон ачылуга рөхсәт бирелү сәбәпле, республикада туристлар агымы мөстәкыйль туризм исәбенә сизелерлек артты һәм җәйге айларның туристик сезонына 2 миллионнан күбрәк кеше тәшкил итте, бу 2019 елның шул ук чорыннан өч тапкыр артык.

Федераль әһәмияттәге «Мраткино» бөтенсезон гаилә курорты булдыру буенча инвестор белән концессион килешү төзү көтелә. Зур Кеньяк-Урал сукмагы быел 300 километрга кадәр озынайтылачак.

Вакыйгаларга бәйле туризм өлкәсендә Башкортстан быел Милли премия гран-прием алды. «Павловка сусаклагычы» туристик-рекреацион кластерын булдыру һәм үстерү турында» килешүгә кул куелды (Нуриман һәм Караидел районнары). «Уфа», «Кандракүл», «Төньяк-Көнчыгыш», «Нөгеш», «Асылыкүл» туристик-рекреацион кластерларын булдыру һәм үстерү буенча проект алды эше алып барыла.

## Айныткычлар системасы яңартылачак

«Алкоголь, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү буенча Русия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон үз көченә керде. «Закон ил субъектларына һәм муниципалитетларга медицина айныткычларын булдыру буенча вәкаләтләр бирә, – дип аңлатты БРның Дәүләт Җыелышы-Корылтай рәисе К.Б.Толкачев. - Полиция хезмәткәрләренә анда исерек кешеләрне китерү хокукы бирелде. Айныткычларның эш форматын төбәкләр мөстәкыйль билгеләргә тиеш булачак. Мәсәлән, алар дәүләт-шәхси партнерлык принципларында булдырылырга мөмкин». Республика парламенты спикеры сүзләренчә, мондый учреждениеләр кирәк, әмма аларның форматын төрле яклап анализлау мөһим.

Айныткычларның эшчәнлек кагыйдәләре РФ Хөкүмәте тарафыннан расланачак.

## Крещение суыклары

Атнаның иң салкын көне 15 гыйнварда көтелә, көндез республиканың үзәк районнарында 26-27 градус салкын булачак, ә төнлә термометр баганасы минус 33 градуска кадәр төшәчәк. Алдагы көннәрдә бераз җылыначак. 16-18 гыйнварда республикада көндезге сәгатьләрдә - 20, төнлә 25 градуска кадәр салкын булачак. 19 гыйнварда, Крещениегә, якынча шундый ук һава торышы, бераз кар явуы көтелә. Күпьеллык метеокүзәтүләр буенча, гыйнварның икенче яртысы безнең климатик полосада елның иң салкын чоры була. Бу вакыттагы көчле салкыннар башлануы еш кына крещение суыклары дип атала.

# Планда – Программада катнашу

Урындагы башлангычларны хуплау программасы елдан-ел безнең тормышыбызга ныграк керә һәм авыл кешеләренең проблемаларын хәл итәргә ярдәм итә.

Тактагул авыл Советы авыл биләмәсе бу программада бишенче ел рәттән катнаша. Шушы еллар эчендә проект ярдәмендә Тактагул авылында янгын сүндерү техникасын саклау өчен бина барлыкка килде, Мәктәп һәм Береговая урамнары юлы төзекләндерелде, Гүрдебаш һәм Кандалакбаш авылларында зиратларга капиталь ремонт ясалды. Программа кысаларында барган уңай үзгәрешләрне күреп, республика, район хакимияте, иганәчеләр ярдәмен тоеп, халык яңа идеяләр белән илһамлана, яңа проектлар планлаштыра. Кыскасы, авыл халкы 2021 елда да программада катнашырга әзер. Урындагы башлангычларны хуплау программасында катнашу өчен барлык авылларда да башлангыч эш алып барылды - гражданнар җыеннары, анкеталаштыру үткәрелде, алар барышында беренче чиратта хәл ителергә тиешле иң мөһим мәсьәләләр турында фикер алыштылар. Гражданнарның күпчелеге Бөек Ватан сугышында катнашучыларга Тактагул авылында яңа һәйкәл кую өчен тавыш бирде.

Тактагул авыл Советы авыл биләмәсенең 2021 елда урындагы башлангычларны хуплау программасында катнашу өчен проектны сайлау йомгаклау җыелышында булды. Халык «Бөек Ватан сугышында катнашучыларга яңа һәйкәл кую» проектын бертавыштан хуплады. Билгеләнгән эшләрне башкару өчен 500 мең сумга якын акча кирәк. Аларны республика һәм урындагы бюджетлардан финанслау исәбенә, шулай ук иганәчеләр һәм халык үз кертkән өлеш исәбенә туплау күз уңында тотыла.

Проектны тормышка ашыру өчен 4 кешедән торган инициативалы төркем булдырылды. Ул урындагы башлангычларны хуплау проектын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда ярдәм итәчәк, халык белән эш алып барачак. Уртак эшкә үз өлешләрен кертергә теләгән якташлар, иганәчеләр дә табылыр дип өметләнәбез. Эшнең уңышлы килеп чыгасына ышанабыз.

**Лилия АХУНОВА,**
**Тактагул авыл Советы авыл биләмәсе башлыгы.**

◆ Хәвефсезлек

# Крещение бәкесендә коенып чыгарга теләүчеләргә

**Бәкедә коену - Аллаһы крещениесе көнендәге гореф-гадәтләрнең берсе. Бу халык йоласы символик мәгънәгә ия һәм мәҗбүри түгел.**

Системалы рәвештә салкын суда коену организмны савыктыруга ярдәм итә, ә менә елга бер тапкыр кышын бәкегә чуму - организм өчен көчле стресс.

Крещениедә коенырга ниятләгән кешеләр өчен түбәндәге кагыйдәләрне үтәргә киңәш ителә: әгәр балагыз үзегез белән булса, аны караучысыз калдырмагыз, аның олылар күзәтүеннән башка коенуына юл куймагыз; су керү өчен махсус җиһазландырылган һәм коткару хезмәтләре хезмәткәрләренең дежурлыгы тәэмин ителгән урыннарда гына коенырга ярый. Коенганчы, аның вакытында һәм аннан соң алкоголь куллану рөхсәт ителми. Бәкедә су коеныр алдыннан разминка ясап, йөгереп, тәнне җылытып алырга кирәк; бәке янына уңайлы, таймаган һәм җиңел салынган аяк киеме киеп килергә. Суга илткән сукмакның тайгак булу ихтималын исегездә тотыгыз, акрын атлагыз. Организмның гомуми суынуын булдырмас өчен, суда 1 минуттан да артык тормаска киңәш ителә. Сакчыллык һәм ярдәм кирәк. Судан чыккач, үзеңнең һәм баланың тәнен йомшак сөлге белән сөртеп, коры кием киегез. Иммунитетны ныгыту һәм организмның суынуын булдырмау өчен, кайнар чәй эчегез, иң яхшысы - җиләк-җимештән кайнатылганы.

Чиркәүдә дә хәвефсезлек чаралары турында истә тотарга кирәк.

Шәм кабызганда, җиңнәрне күтәреп куярга, эрегән шәм тирегә эләгеп, кулны кискен тартып алып, янган шәмне киемгә төшермәс өчен, аның астында кәгазь кисәге яки кульъяулык тотарга. Яулыкларны яхшылап бәйләгез һәм чәчләрне җыегыз. Янган шәмне киемегез янына китермәсеннәр өчен, балаларны күзәтеп торыгыз. Башка кешеләрдән хәвефсез араны саклагыз, бер урында тупланмаска тырышыгыз.

Әгәр храмда янгын сигнализациясе эшли башласа - курыкмаска, паникасыз гына бинадан ашыгыч рәвештә чыгарга кирәк.

**Фларид ЯМАЛОВ,**
**янгын күзәтчелеге буенча дәүләт инспекторы.**

*Авыр эпидемиологик хәлгә бәйле рәвештә, быел Аллаһы крещениесен бәйрәм иткәндә храмнарда бәйрәм хезмәтләрен оештыруда берничә мөһим үзенчәлек булачак.*

*Гыйбадәтләр вакытында бер үк вакытта дини объект эчендә булган гражданнар саны, шул исәптән руханилар һәм гыйбадәтханә хезмәткәрләре, дүрт квадрат метр мәйданга бер кеше нормасыннан исәп тотарга киңәш ителә.*

*Чиркәү биналарына керү юлында профилактика максатларында кулларны эшкәртү өчен антисептиклар булырга тиеш, гыйбадәттә катнашучыларның барысы да маска кияргә тиеш.*

*Профилактика максатларында бинаны даими җилләтергә һәм дымлы җыештыру эшләре башкарырга кирәк. Иконалар дезинфекция чаралары белән эшкәртелергә тиеш.*